# Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында карар

**17 ноябрь 2023 ел**

**№4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

"Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кшкар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

Кышкар авылында Мира, Мостовая, Победа урамнарының урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

"ӘЙЕ" "КАРШЫ"

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 150 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 80 граждан кертелде.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 80 кеше тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кышкар торак пунктында гражданнар җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.
2. "Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге Кшкар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук

махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыелган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

Кышкар авылында Мира, Мостовая, Победа урамнарының урам-юл челтәренә вак таш җәеп, автомобиль юлларын тигезләү;

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

соравы буенча карар кабул ителде дип санарга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә Яңа Кишет авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы, Арча районы, Кышкар авылы, Яңа урам, 125 йорт адресы буенча, Арча муниципаль районның (http:// arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгы ____________ Ф.И.Ахмадуллин
(имза)(имзаның аңлатмасы)